**КАРАР**

**“12” ноябрь 2021 ел№ 8**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Күкчә-Бирәзә авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,2021 елның ,12 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

««Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Күкчә-Бирәзә авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 750 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан тыш,1500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

-- юл-урам челтәре нигезен вак таш-грунттан каплау: Тынычлык урамының 3 йортыннан 9 йортына кадәр- 130м, Үзәк урамның 1 йортыннан алып күпергә кадәр-300м.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Халык җыены беркетмәсе(йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 81 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 41 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 40 кеше тавыш бирде;
“Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 1 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Күкчә-Бирәзә авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. ««Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Күкчә-Бирәзә авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 750 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан тыш,1500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

-- юл-урам челтәре нигезен вак таш-грунттан каплау: Тынычлык урамының 3 йортыннан 9 йортына кадәр- 130м, Үзәк урамның 1 йортыннан алып күпергә кадәр-300м.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”»

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Күкчә-Бирәзә авылы, Үзәк урам, 4 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров